ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» 01 2020 г. № 12

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Шубан авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча гавами (ачык) тыңлаулар үткәрү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24, 28 статьялары, Балтач муниципаль районы Уставының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2007 елның 24 мартындагы 66 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гавами тыңлаулар үткәрү турында» Нигезләмә нигездә, кешенең уңай тормыш шартларына хокукларын, «Шубан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында Балтач муниципаль районы башлыгы карар бирә:

1. Шубан авыл җирлеге халкы катнашында «Шубан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Югары Шубан һәм Түбән Шубан авыллары гражданнары өчен «Шубан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлауларны 2020 елның 15 февралендә 10:00 сәгатьтән 10:30 сәгатькә кадәр Югары Шубан мәдәният йортында түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Балтач районы, Югары Шубан авылы, Үзәк урам, 31 нче йорт.

3. Гондыр, Ярак-Чурма, Зур Лызи-2 авыллары гражданнары өчен «Шубан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлауларны 2020 елның 15 февралендә 11:00 сәгатьтән 11:30 сәгатькә кадәр Ярак-Чурма авыл клубында түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Балтач районы, Ярак-Чурма авылы, М.Горький урамы, 43 нче йорт.

4. Балтач муниципаль районының « Шубан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең территорияне территориаль планлаштыруның шәһәр төзелеше документларын әзерләү буенча комиссиясенә (алга таба - Комиссия) гавами тыңлаулар үткәрүне оештырырга.

5. Комиссиягә «Шубан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы буенча демонстрацион материаллардан күргәзмә-

экспозицияләр оештырырга, гавами тыңлаулар тәмамланганнан соң, тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә.

6. Генераль план проекты буенча гражданнардан тәкъдимнәр әлеге карар басылып чыкканнан соң бер ай эчендә Шубан авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Балтач районы, Югары Шубан авылы, Үзәк урам, 33 нче йорт.

7. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының baltasi.tatar.ru рәсми сайтында һәм Шубан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Балтач
муниципаль районы башлыгы — Р. Р. Нотфуллин